**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше системасы нәтиҗәлелеген арттыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасы турында» 2018 елның 18 августындагы ПУ-574 номерлы Указының 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«дәүләт органы, җирле үзидарә органы соравы буенча стажировка мәйданчыклары системасында әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировкасы оештырыла;»;

б) алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 10 сентябрь
№ ПУ-574